# Нәсыйхәт

җомга 25 март 2011 № 2

Рәхимле вә Шәфкатьле АЛЛАҺ исеме белән
Мамадыш мәдрәсәсенең айлык дини-иҗтимагый газетасы




# Дин гыйлеме–сүнмәс маяк

**Мәдрәсә–белем учагы. Ул учак бар кешеләрне җылыта, аларга бу дөньяда үз урыннарын табарга ярдәм итә.**

Әгәр дә бу учакны яр буендагы маяк белән чагыштырсак, ул океандагы корабларга бик ерактан ук күренеп торыр. Әгәр үзебезне ракеталар белән чагыштырсак, белем – аның ягулыгы. Әмма “белем” дигән ягулык тиз генә бетми. Ул сине гел өскә, югарыдан-югарыга гына күтәрә. Кешеләргә әйт: ”Батылны белеп батылдан ерак булган, хакны белеп хак тарафында сабит булган хак мөэминнәр, батылны да, хакны да белмичә адашып йөргән сукырлар илә бер тигез булырлармы? Хакны батылдан аеру хакында саф акыллы кешеләр генә вәгазьләнерләр һәм батылдан (ялганнан) бизеп, хакны кабул итәрләр”. (Халык төркеме, 9 аять). Аллаһ Сөбхәнә вә Тәгалә Коръәни –Кәримдә бик күп тапкыр гыйлем һәм ул гыйлемне алучылар, аны эзләүчеләр турында искә ала. Әгәр дә Гыймран сүрәсенең 11нче аятенә күз салсак, Аллаһ Сөбхәнә вә Тәгалә гыйлем ияләрен фәрештәләр белән бер тигез дәрәҗәдә зекер итә: “Аллаһ үзе вә фәрештәләр һәм хакыйкый чын галимнәр : “Кол булырга яраклы Иләһ юк, иллә мәгәр Аллаһ үзе генә,” - дип дөреслек белән һәм көчле исбатлау белән шәһадәт бирәләр. “Аллаһ Сөбхәнә вә Тәгалә, иң беренче чиратта үзен зекер итә. Аннары икенче фәрештәләрне атады, ә аннары - гыйлем ияләрен. Ягъни әйтәсе килгән фикерем шул ки: кемнәр белемне эзли, өйрәнә һәм шул белемне тормышта куллана, аны калганнарга да тарата икән, Аллаһ каршында аның дәрәҗәсе фәрештәләрнеке кебек тә була ала. Пәйгамбәребез белемне яңгыр белән чагыштыра. Ул яңгыр үзе белән яхшылык һәм бетмәс нигъмәт алып килә. Һәм ничек итеп бу яңгыр үле җирне терелтә, шулай ук белем дә “үле” йөрәкләрне терелтә. Мәкаләмне пәйгамбәребезнең бер хәдисе белән тәмамлыйсым килә. “Кем дә кем берәр юлга белем алырга дип чыкса, Аллаһ аңа җәннәткә юлны җиңеләйтәчәк һәм дөреслектә, фәрештәләр, һичшиксез, үзләренең канәгать булуларын күрсәтү өчен аның өстеннән канатларын җәячәкләр һәм дөреслектә, бөтен күк һәм җир әһелләре, хәтта судагы балыклар да бу кеше өчен Аллаһтан гафу сорый башлыйлар. Ә гыйбадәт кылучы белән гыйлем иясенең аермасына килгәндә, ул айның яктылыгы белән калган яктыртучылар яктылыгы аермасы сыман, һәм бу кешеләр пәйгамбәрләрнең варислары булып торалар. Ә алар үзләреннән мирас (милек) итеп динарлар һәм дирхамнар түгел, ә гыйлем калдыралар, ә кем бу мирасны ала, аңа бик зур өлеш тия.”

**ЛЕНАР ХАММАТОВ,**

**2 нче курс шәкерте.**

## Хәбәрләр

+Һәр айның беренче чәршәмбесендә уза торган имамнар җыелышының беренче сәгате дәрес формасында үтә. Әлеге практик дәресләрдә дини йолаларны үтәү практикасы, аларның сыйфатын яхшырту, гыйбадәт кылу тәртипләре өйрәтелә. Мәдрәсәнең мөгаллимнәре район имамнарының белемен арттыруда зур өлеш кертәләр.

+16нчы март көнне мәдрәсә бинасында яшь мөселман гаиләләре катнашында түгәрәк өстәл булды. Фикер алышуда балалар бакчасында хәләл ризык белән тукландырыла торган мөселман балалар төркемен булдыру ихтыяҗы һәм әлеге максатка ирешү юллары турында сүз барды.

+Авыл мәчетләренә барып җомгалар уздыруда шәһәр имамнары белән берлектә мәдрәсә мөгаллимнәре дә катнаша. Әле узган атналарда Урта Кирмән, Югары Сон, Кече Сон, Түбән Сон, Баскан авылларында үткән җомгалардан халык бик канәгать калды. Җомгалар уздырырга шулай ук югары курс шәкертләре дә җәлеп ителә. Мәдрәсә шәкертләре шәһәр мәчетләрендә практика үтүләрен дәвам итә.

+20 нче мартта Изге Нур” мәчетендә мәдрәсә мөгаллимнәре һәм шәкертләре катнашында Коръән уку бәйгесе узды. Бәйге “Изге Нур” мәчете имам-хатыйбы Мансур хәзрәт тарафыннан оештырылды.

+Мәдрәсәдә шәкертләр өчен умартачылык түгәрәге эшли.

# Ялганга корылган индустрия

**Соңгы вакытта багучылык, алдагысын әйтеп бирү күренешләре киң таралды.**

Теләсә нинди газетаны ачуга шундый белдерүләр күзгә чалына: "Күрәзәче сезнең язмышыгызны сөйләп бирер" яки "Тәҗрибәле астролог киләчәкне юрый". Белдерүнең "Югары категорияле сихерче сезнең өчен көн саен йолдызнамә төзи", «Проблемаларыгызны хәл итәбез» кебекләре дә бар. Телевизорны ачсак та, "йолдызлар фаразы" әйтәләр. Һәр журналда атналыкмы, айлыкмы йолдызнамә бирелеп бара. Бүгенге газета-журналларда, телевидение һәм интернетта түбәндәге эчтәлекле белдерүләр бихисап: "алдагысын сөйләп бирәм", "сихерне алып ташлыйм", "иреңне кайтарам", "нәселгә кучкән сихердән коткарам" һәм башкалар. Миллионлаган данәдә күрәзәчелек, багу һәм сихергә өйрәтә торган китаплар бастырыла. Шуңа күрә, теләсә кем сихерче, багучы, алдагысын әйтеп бирүче була ала. Еш кына кешеләр, авыр хәлгә юлыккач, югалып калалар. Кая барып бәрелергә, кемгә мөрәҗәгать итәргә белмәгәнлектән, соңгы чарага–багучыларга, экстрасенсларга һәм башка "белгеч"ләргә мөрәҗәгать итәләр. Аларга өметләнәләр, аларның ниндидер серле көче барлыгына чын күңелдән ышаналар. Бу очракта бер хакыйкатьне онытмаска кирәк: бары тик Аллаһы Тәгалә генә кешеләрнең язмышларын, алдагысын белә. Бу сүзләргә дәлил Коръәндә бирелгән: "Яшерен нәрсәләрне белү ачкычы Анда гына, Аннан башка беркем дә аларны белми" (27:65) яки "Яшерен нәрсәләрне белүче, Илчеләрнең кайберләреннән башка, беркемгә дә бу серләрне ачмый" (72:26-27). Бу мәсьәлә буенча ислам галимнәренең сүзләренә дә колак салыйк: "Йолдызларның юнәлешенә карап фаразлау, киләчәкне юрау, сихерчелеккә караган һәрнәрсә дә ислам дине буенча тыелган". Монда шуны да онытмаска кирәк: күрәзәчеләргә ышанган кеше аларга психологик яктан бәйле була. Ул бәйлелек һаман саен арта бара ки, кеше күрәзәчеләрнең сүзләренә генә карап, үзе бернәрсә дә уйламый башлый, ирекен, фикер хөрлеген югалта. Йолдызнамәгә табына башлый. Ислам дине мондый түбәнчелекле коллыкның рухның зәгыйфьләндерүен искәртә һәм йолдызнамәне укуны, аңа ышануны тыя.

## Астрология ялганга нигезләнгән

Астрология, йолдызнамә белән шөгыльләнү генә түгел, ә экстрасенслар янына бару, күрәзәчеләргә ышану, йолдызнамә уку, астрология буенча китаплар сатып алу да тыела! Чираттагы газетадан үз йолдызнамәсен эзләүчегә Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) түбәндәге сүзләрен җиткерәбез: "Кем багучы янына килеп, нәрсә булса да сораса, аның намазы 40 көн буена кабул булмый". Бу хәдис Мөслим җыентыгында китерелә. Йолдызнамәләргә ышанган кешене кяфергә дә тиңләү бар. Чөнки Мөхәммәд (с.г.в.) бу уңайдан болай дигән: "Кем сихерче һәм багучыга барып, аларга ышана, шул имансызлык белдерде дигән сүз". Ошбу хәдис Әбү Хөрәйрә, Әхмәт белән Әбү Давыт җыентыкларында да бар. Астрологиягә ышану, йолдызнамәләр төзү исламга каршы килә. Багучы һәм астрологлар киләчәкне беләбез, дип әйтергә ярата. Чынлыкта алар – проблемалардан котылу өчен ялган мөмкинлек кенә. Кайберәүләр йолдызнамә әйткәч, иртәгә нәрсә буласын беләбез, шуңа күрә күңелсезлекләргә алдан ук әзерләнеп куябыз, дип уйлый. Ләкин Аллаһ илчесенә болай дип әйтергә куша: "Әгәр дә мин яшерен нәрсәләрне белсәм, байлыгым артыр иде, беркайчан да миңа бәхетсезлек килмәс иде. Ләкин мин динне иманлы бәндәләргә җиткерүче генә" (Пәрдә, 7:188). Шулай итеп, астрология һәм йолдызнамә ялганга нигезләнгән, аның бернинди дә фәнни нигезе юк. Астрологларның, сихерчеләрнең кешеләрне ышандырыр һәм гамәлләренең "фәнни" булуларын раслар өчен компьютерны куллануы фокус күрсәтүченең эшенә генә охшап кала. Туган вакытында йолдызларның ничек урнашкан булуы белән кеше язмышы, аның характеры арасында булган бәйләнеш хакында бернинди дә фәнни дәлил юк. Кодс шәһәре Университетының фикһ нигезләре буенча профессор, доктор, мөфти Хасамаддин ибн Муса Афан әйтүенчә, тарихта астрологларның сүзләре ялганга чыккан вакыйгалар күп булды. Мәсәлән, Габбасидларның хәлифе әл-Мотасим Аммурияне басып алырга теләгән. Астрологлар аңа бу вакытта сугыш башламаска киңәш итәләр. Аның өчен уңышсыз вакыт, диләр. Ләкин ул астрологларны тыңламаган һәм җиңүгә дә ирешкән. Астрологларның башка күп төрле сүзләре дә ялган. Мәсәлән, күрәзәчеләрнең сүзенә ышансак, дөнья инде әллә кайчан беткән булыр иде. Кайберәүләр бу вакыйганы 1986 елда булачак, дип фаразлады. Кемдер 2000 елга тәгаенләде. Әмма дөнья әле дә бетмәгән. Сугыш башлануы турында да хәбәрләр гел булып кына тора.

## Вангага һәм Нострадамуска ышаныргамы?

Бүген еш кына Вангага һәм Нострадамуска киләчәкне күрү сәләте Аллаһ тарафыннан бирелгән дигән сүзләрне ишетергә туры килә. Бәлки, шуңа күрәдер кайбер мөселманнар аларга уңай карыйлар һәм хөрмәт итәләр. Әмма бу ялганчы багучылар исламнан бик ерак торалар бит, эшмәкәрлекләрен дә ислам диненнән ерак булган кануннар буенча алып баралар. Аларның киләчәкне әйтүләре нидән гыйбарәт дигән сорауны үз-үзегезгә биргәнегез бармы? Эш шунда ки, танылган күрәзәчеләр (мәсәлән, Нострадамус, Эдгар Кейси, Павел Глоба) үзләрен Аллаһ белән бертигез куялар. Шуның белән алар хәдисләрдәге сүзләргә каршы киләләр. Әлбәттә, кайбер очракта аларның сүзләре чынга аша. Ләкин, алар бар нәрсәне дә төгәл итеп әйтмиләр, еш кына кешенең наданлыгыннан файдаланалар. Мәсәлән, Нострадамус белән Ванга дөньяның кайчан бетәчәген күпме генә әйтергә тырышса да, булдыра алмады. Чөнки Аллаһ каршында кайчан җавап бирәчәгебезне беркем дә белми. Әбү Хөрәйрәдә бер хәдис бар: "Мөхәммәд пәйгамбәр янына кеше кыяфәтендә Җәбраил фәрештә килә дә: "Кыямәт көне кайчан җитә?"-дип сорый. "Җавап бирүче сорау бирүчедән күбрәк белми. Мин аның билгеләрен генә әйтә алам: кол хатын-кыз үзенең хуҗасын тудырыр, кара дөя көтүчеләр биек йортлар төзүдә ярышыр...

**ГАБДРАХМАН ХӘБИБУЛЛИН,**
**баш мөхәррир.**

**(Дәвамы киләсе санда).**

"Кем багучы янына килеп, нәрсә булса да сораса һәм аның сүзләренә ышанса, намазы 40 көн буена кабул булмый".

Мөслим риваятеннән.

# Борынгы Болгарга сәяхәт

**Узган елның матур җәй аенда без, бер төркем мәчет әһелләре һәм халкыбызнын тарихы белән кызыксынучылар, изге Болгарга юл алдык.**

Искиткеч гүзәл, матур иртә. Безнең күзләрне сөендереп, күңелләрне канатландырып, искиткеч манзаралар озата бара. Юлыбыз урманнар, ерганаклар, инешләр, таныш булмаган авыллар аша дәвам итә. Котлы Бөкәш, Балык Бистәсе, Саескан тавы... Чулман елгасы аша салынган берничә чакрымга сузылган күпер шулкадәр мәһабәт. Ә яшькелт төстәге чал елга күбекләнә-күбекләнә үзенең буйсынмас көчен күрсәтә. Аның өчен горурлыктан күзләргә яшь килә.

Сәгать унда без изге Болгар җиренә аяк бастык. Андагы халык, халык.... Машиналарның, автобусларның исәбе-хисабы юк. Мөселманнарның җыенына Россиянең төрле төбәкләреннән килгәннәр. Ираннан, гарәп илләреннән, Төркиядән дә кунаклар бар. Беренче Президентыбыз Минтимер ага Шәймиев, Уфадан Тәлгать Таҗетдин, Мәскәүдән Равил Гайнетдинне күрергә һәм чыгышларын тыңларга насыйп булды. Алар Болгарның зур төзелеш мәйданына әверелəчәге, биредә күп кенә тарихи объектлар торгызылачагы турында сөйләделәр. Бүген без андагы яңалыкларның һәммәсеннән хәбәрдар булып торабыз, үзгәрешләр шактый. Мөселманнарның борынгы Болгар һәм христианнарның Зөя шәһәрчегендәге тарихи-архитектура һәйкәлләрен торгызуга бөтен халык алынды. Экскурсоводларга ияреп без Болгар шәһәрчегенә сәяхәт тә ясадык. Әллә кайларга кадәр сузылган тигезлектә корылма калдыклары, шәһәрне көньяк һәм көнчыгыштан биек вал чорнап алган. Манараларның кечкенәләре дә, зурлары да сакланган. Нигезенә мөселман кабер ташлары куелган чиркәү музей ролен үти. Кырыйда чал Идел җәйрәп ага.

Безнең борынгы бабаларыбыз нәкъ шушы искиткеч җирләрдә гомер кичергәннәр бит инде.

Олы манара янына җыелып өйлә намазы укыдык. Хөрмәтле Илһам хәзрәт–мөхтәсибебез безнең алда иде. Аңа Аллаһы Тәгаләнең зур рәхмәтләре булсын. Игътибарга лаек нәрсә: Чувашиядән, Пенза өлкәсеннән килгән кардәшләр зур-зур казаннарда пылаулар пешереп, халыкны сыйладылар. Монысын безгә дә оештырырга кирәк. Быелгы җәйдә дә Болгар җыенында мамадышлыларга күпләп катнашырга Ходай насыйп итсә иде.

**Сабирҗан Әхмәтҗанов,**

**кичке 2нче курс төркем шәкерте.**



# Мәдрәсәгә илткән юллар...

*Һәрбер эшләгән эшнең, һәр кылган гамәлнең үз сәбәбе бар. Белгәнебезчә, мәдрәсәбезгә төрле яшьтәге, төрле һөнәр ияләре булган хатын-кыз һәм ир-атлар белем алырга килә. Аларны бирегә нинди сәбәпләр алып килде икән? Әнә шул сорау белән мин беренче курс шәкертләренә мөрәҗәгать иттем.*

**Мөнирә Нәбиуллина, администратор:**

–“Яңа гасыр” радиосындагы “Хикмәти дөнья” тапшыруында катнашып бүләккә лаек булдым. Миңа Коръән китабы бирделәр. Аны гарәпчә укыйсым килде. Шул сәбәпле мәдрәсәгә йөрергә булдым. Мәчеткә хезер салырга кергәч, озакламый укулар башланачагын әйттеләр. Аллаһның рәхмәте белән мин шулай укырга йөреп киттем.

**Зәйнәп Имаметдинова, пенсионер:**

– Минем әнием дә укуымны бик теләгән иде. Бүгенге көндә инде ул мәрхүм. Шуңа күрә, үлгәч булса да, әниемнең хыялы тормышка ашсын дип, мин укырга килдем. Үземнең дә теләгем бик зур. Сәңлем дә биредә икенче курста белем ала, мин аңа да бик кызыгып йөри идем. Шулай итеп, укуыма сеңлем дә, әнием дә этәргеч булды.

**Әлфия Габделбәр кызы, пенсионер:**

–Монда килүемнең сәбәбе тормышымдагы авырлыклар булды. Сәламәтлегем какшады, пенсиягә чыккач эшне дә сагынып йөрдем. Аллаһның ярдәме белән монда килеп мин үземә тынычлык таптым. Мәдрәсәгә бер көн дә калдырмыйча килеп, өйрәнәсем, гыйлем аласым килә. Алга таба да гыйлемнәребезне арттырырга Аллаһы Тәгалә барыбызга да ярдәм бирсен.

**Сорашуны Эльвира ХӘБИБУЛЛИНА уткәрде.**

**(Дәвамы киләсе санда).**

## Сорау илә җавап

**–Әһле исламга мөселманнарныкы булмаган гыйбадәтханәдә, әйтик, чиркәүдә, синагогада намаз укырга ярыймы? Мәсәлән, янәшәдә генә мәчет булмаган чит урында намаз вакыты керергә мөмкин. Шул ук вакытта урамда юеш һәм пычрак булса нишләргә?**

–*Пәйгамбәребезнең бер хәдисендә мөселман өчен бөтен Җир шарының мәчет булуы турында әйтелә. Димәк, без барлык урында да намаз укый алабыз. Бары тик ул җирнең нәҗестән чиста булуы гына шарт итеп куела. Әгәр берәү озын-озак юлга чыгып, сәфәре вакытында аңа бернинди дә мәчет очрамаса, ул намазны үзенә уңайлы булган теләсә нинди урында, шул исәптән, мөселманнарныкы булмаган храмнарда да укырга мөмкин. Иман йортлары аз булган РФнең кайбер төбәкләре өчен бу мәсьәлә аеруча мөһим.*

**–Минем эти тагын өйләнде. Үги әнинең кызы бар. Миңа ул кызга өйләнергә мөмкинме?**

–*Мөселманга үги анага яисә тәрбиячесенә өйләнергә ярамый. Ә үги ананың кызына яисә тәрбиячесенең кызына өйләнүдән гөнаһ юк.*

**–Кунакка баргач, алга китереп куйган ризыкның хәләлме икәнлегенә мин еш кына шикләнеп карыйм. Хуҗа кешедән бу терлекнең мөселманча суелганмы яисә суелмаганлыгы турында соравы уңайсыз була. Ризыктан баш тарту да яхшы түгел кебек. Бу очракта нәрсә эшләргә?**

–*Әгәр дә намаз укучы мөселманнарга кунакка килсәгез һәм ризыкның хәләллегенә шикләнсәгез, бу хакта сорарга кирәкми. Әгәр дә этник мөселман булып саналган кешеләргә кунакка килсәгез, алардан итагатьле генә итеп, тегe яки бу ризыкның хәләллеге турында сорый аласыз.*

**Мәгълүмат tatar-islam.ru сайтыннан кыскартып алынды.**

# Җиңүчеләр билгеле

## Газетабызның беренче санында басылган викторина җаваплары

1. Шамаилдә “Лә иләһә илләллаһ Мөхәммәдүр расүлүллаһ” дип язылган.
2. Аллаһы Тәгаләнең 99 исеме бар.
3. Мөхәммәд пәйгамбәр 570нче, 571нче (кайбер чыганакларда) елда туа.
4. Әнисе үлгәндә пәйгамбәребезгә алты яшь була.
5. Коръән Кәрим исемнәре: Коръән, Фуркан, Тәнзил, Китаб, Зикер.
6. Көннәрнең солтаны – җомга.
7. Пушкинның “Подражание Корану” исемле шигыре бар.
8. Әбү Бәкер, Гомәр, Госман, Гали – дүрт хәлифәнең исеме.
9. Нух пәйгамбәр 2500 ел яшәгән.
10. Коръәни Кәримдә 114 сүрә бар.
11. Каюм Насыйри, Шиһабетдин Мәрҗәни, Ризаэтдин Фәхретдин.
12. Коръән Рамазан аенда иңә башлаган.
13. Пәйгамбәребезгә вәхи иңә башлаганда аңа 40 яшь була.
14. ”Бәкара” – Коръәннең иң озын сүрәсе.
15. Пәйгамбәребезгә вәхи Җәбраил фәрештә аркылы иңә.
16. Коръән сүзенең гарәпчәдән тәрҗемәсенең берсе “Укылды”.
17. Беренче пәйгамбәр Адәм була.
18. Пәйгамбәребезнең сөт анасының исеме Хәлимә.
19. Ислам динен беренчеләрдән кабул иткән ир-атның исеме Әбү Бәкер.
20. Намазны кыйбла тарафына, Мәккәгә, Кәгъбәтуллага карап укыйлар.
21. Ислам календаре Пәйгамбәребезнең Мәккәдән Мәдинәгә күчүеннән башлана.



**Рәсемдә: викторина җиңүчеләре “Нократ” газетасы баш мөхәррире урынбасары Вәрис Гали һәм китапханәче Рәмзия Биктаһировага мәдрәсә директоры Габдрахман Хәбибуллин бүләк тапшырды.**
**ЭЛЬВИРА ХӘБИБУЛЛИНА фотосы.**

## Белдерүләр

+Мәдрәсә базасында атнаның һәр ялында балалар өчен әхлак дәресләре алып барыла. Укуларга рәхим итегез.

+ Мәдрәсә бинасында ислам атрибутикасы кибете эшли. (Коръән китаплары, шамаилләр, тмин майлары, дисбеләр, дини китаплар, түбәтәйләр һ.б.)

+Мәдрәсә базасында таныштыру бүлеге эшли. Тел. 89625504168, 89372991485

+Хәләл кафе хезмәтен күрсәтә (М. Җәлил ур 8/28).
Үзегезне хәләл ризыктан мәхрүм итмәгез!

+ Балага исем кушу, никах уку һәм башка дини мөрәсимнәрне үткәрү. Мамадыш мәдрәсәсе, М. Җәлил ур 8/28.

+ Намаз, Коръән укырга, дин гыйлемен өйрәнергә теләгән һәр кешене мәдрәсәдә оештырылган кичке уку курсларына чакырабыз.

+ Мамадыш мәдрәсәсе фәкыйрь, мескеннәргә, ятим балаларга тарату өчен кулланылган киемнәр кабул итә.

## Кадерле укучыларыбыз, сезгә Ислам тематикасына кагылган яңа викторина сорауларын тәкъдим итәбез.

1. Бәдер сугышында ничә сәхәбә катнашты.
2. Җәннәттән куылгач Адәм һәм Һава кайда очраштылар.
3. Нинди сәхәбәнең хәлифәлек чорында Коръән бер китап булып тупланган?
4. Ничәнче елда һәм кем тарафыннан беренче тапкыр азан әйтелде?
5. Нинди өч гамәл кеше вафат булганнан соң да аңа файда китерә?
6. Пәйгамбәребезнең вафатыннан соң үзен пәйгамбәр дип игълан иткән кешенең исемен атагыз.
7. Ухуд сугышы ничәнче елда булган?
8. Бәдер сугышында Аллаһ мөселманнарга ничек ярдәм иткән?
9. Нинди пәйгамбәр балачактан кошлар ясап аларны терелтү сәләтенә ия булган?
10. Коръәннең нинди сүрәсендә шайтанның җен токымыннан икәнлеге турында әйтелә?
11. Иң беренче төзелгән мәчет ничек аталган?
12. Мәккә шәһәренең Коръәндә зекер ителгән икенче исеме нинди?
13. Кайсы ике сүрә җеннәрдән һәм сихердән саклану өчен укыла?
14. Коръәннең кайсы сүрәсе бөҗәкләр исемен йөртә? Аларны атагыз.
15. Адәмнең (г. с.) ике олы улының исеме ничек?
16. Ибраһим (г.с.) пәйгамбәрлек иткән чорда Гыйракның идарәчесе кем булган?
17. Муса пәйгамбәргә вәхи иңгәндә аның халкы кемгә табынган?
18. Коръәнне яттан белгән кешеләрне ничек атыйлар?
19. Кайсы вакытта Гайсә (г.с.) беренче тапкыр үзенең пәйгамбәр икәнлеген игълан иткән?
20. Коръәннең ничә сүрәсе пәйгамбәрнең исеме белән аталган? Аларның исемнәре ничек?

## Игътибар: конкурс!

**“Нәсыйхәт” газетасы ислам тематикасына багышланган “Иң яхшы дини мәкалә” һәм “Иң яхшы дини шигырь” дип аталган конкурс игълан итә. Җиңүчеләрне истәлекле бүләкләр көтә. Катнашучыларның иҗат җимешләре газетабызда бастырылачак. Мәкаләләр һәм шигырьләр 23 нче апрельгә кадәр кабул ителәләр. Аларны мәдрәсә электрон почтасына яки хат рәвешендә җибәрергә мөмкин. Безнең адрес: М. Җәлил ур. 8/28 Эл. почта: mamadysh-medrese@mail.ru**

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең Бөек исемнәре булганга күрә, аны саклап тотуыгыз сорала**

**Баш мөхәррир: Хәбибуллин А.М. Мөхәррир урынбасары: Талипов Р.Р.**
**Дизайн һәм верстка: Мингалиева Ф.Н. Корректор: Спиридонова А.С.**
**Безнең адрес: Мамадыш шәһәре, Муса Җәлил урамы,8/28. mamadysh-medrese@mail.ru. Газета “Татмедиа” ААҖнең Мамадыш муниципаль районы”Нократ” мәгълүмат-матбугат филиалында басылды. Тираж татар телендә 150 данә.**